КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 декабрь г.Казань № 982

Буа муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенең Буа муниципаль районында урнашкан 0,0464 гектар гомуми мәйданлы, шуның - 0,0212 гектары Е.М.Емельянова милкендә, 0,013 гектары – Н.В.Гаврилов милкендә, 0,0024 гектары – «Лидер» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте милкендә, 0,0098 гектары – дәүләт милкендә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә энергетика (электр тапшыру линияләре) объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:14:170104:93 | 0,0098 |
| 16:14:000000:1108 | 0,0212 |
| 16:14:170104:115 | 0,013 |
| 16:14:170104:112 | 0,0024 |
| Барысы | 0,0464. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин